СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРЖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 22 мае Әгерҗе шәһәре № 37-1

“Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль берәмлеге” Уставына үзгәрешләр кертү турында

Әгерҗе районы прокуратурасының 2018 елның 22 ноябреннән 02-01-18-2018 номерлы мәгълүматын һәм Әгерҗе районы прокуратурасының Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Уставына карата 2019 елның 28 мартыннан 02-08-01/32 номерлы протестын күздә тотып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябреннән 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 30 октябреннән 387-ФЗ номерлы Федераль законның 2 һәм 28 маддәләренә үзгәрешләр кертү, “Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 21 һәм 26.3 маддәләренә һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 15 һәм 16 маддәләренә үзгәрешләр кертү хакында 2019 елның 6 февраленнән 3-ФЗ номерлы Федераль закон, 2019 елның 01 маеннан № 85-ФЗ “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында документларга нигезләнеп, Татарстан Республикасы Әгерҗе муиципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләрне икенче укылышта кабул итәргә (кушымта).
2. Әлеге карарны «Әгерҗе хәбәрләре»(“Агрызские вести”) район газетасында дәүләт теркәвенә алынганнан соң бастырып чыгарырга, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы порталында «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» урнаштырырга, (http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://agryz.tatarstan.ru) бастырырга.
3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы Рәисе урынбасары Р.Т.Нурисламовка йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы,

Совет Рәисе

В. В. Макаров

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Советының 2019 елның 22
маеннан № 37-1 номерлы
карарына кушымта

**“Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставында үзгәрешләр**

1. 6 маддәнең 1 өлешендәге 8 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

8) «милләтара һәм конфессияара килешүне ныгытуга, муниципаль район территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен үстерүгә, аз санлы халыкларның һәм башка милли азчылыкларның хокукларын тормышка ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуын тәэмин итүгә, милләтара (этникара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру;»

2. 17 маддәнең 2 өлешен түбәндәге редакциядә бирергә:

2. «Территориаль иҗтимагый үзидарә гражданнарның түбәндәге территорияләре чикләрендә гамәлгә ашырылырга мөмкин: күпфатирлы торак йорт подъездлары, күпфатирлы торак йортлар, торак йортлар төркеме; торак микрорайон; җирлек булмаган авыл торак пункты; шулай ук торак пунктларның авыллар арасындагы территориядә (яисә аларның территорияләре өлешендә) урнашкан торак пункт).»

3.20маддәдә:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бирергә:

«2. Халык алдында тыңлаулар район Советы, район башлыгы яки район Башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә. Халык яки район Советы инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар район Советы тарафыннан, ә район башлыгы яки район Башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы буенча район башлыгы тарафыннан билгеләнә.».

б) 10 өлештә «әлеге маддәнең 3 өлешендә күрсәтелгән проектлар һәм мәсьәләләр буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

4. 29 маддәнең 6 өлешендәге 1 пунктында "сәяси партия" сүзеннән соң "билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюз" сүзләрен өстәргә.

5. 46 маддәнең 6 өлешендәге 18нче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

милләтара һәм конфессияара килешүне ныгытуга, Россия Федерациясе территориясендә яшәүче халыкларының телләрен һәм мәдәниятен үстерүгә һәм аларга ярдәм итүгә, җирле аз санлы халыкларның һәм башка милли азчылыкларның хокукларын тормышка ашыруга, мигрантларның социаль һәм мәдәни җайлашуын тәэмин итүгә, милләтара (этносара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны эшли һәм гамәлгә ашыра;

6. 54 маддәгә түбәндәге эчтәлекле 3нче пункт өстәргә:

«3. Контроль-хисап органы Рәисе, Рәисе урынбасары һәм аудиторы (ата-аналар, хатынының балалары, бертуган, сеңелләре, шулай ук бертуган, сеңелләре, ата-аналары, балаларының балалары) район Советы рәисе, район башлыгы, район Башкарма комитеты җитәкчесе, район территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлыкта була алмый.».